**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_07_» ____06_____ 2024 ел.** **№ _121____**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл җирлегенең Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында (үзгәрешләр кертү)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча (үзгәрешләр кертү) (алга таба - гавами тыңлаулар) гавами тыңлауларны билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы итеп - Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетын;

- генераль план проекты буенча гавами тыңлауларны уздыру вакыты - 18 календарь көн (2024 елның 14 июненнән 2024 елның 01 июленә кадәр).

- генераль план проекты буенча гавами тыңлауларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны:

2024 елның 2 июлендә мәскәү вакыты белән 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: 423320, ТР, Азнакай районы, Кәкре-Елга авылы, Совет урамы, 23 А йорты; Азнакай муниципаль районының Кәкре- Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты;

2024 елның 2 июлендә мәскәү вакыты белән 15.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: 423320, ТР, Азнакай районы, Кәкре-Елга авыл җирлеге, Катыйм авылы, М.Сәхбиев урамы, 18А йорты янында;

2024 елның 2 июлендә Мәскәү вакыты белән 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: 423320, ТР, Азнакай районы, Кәкре-Елга авыл җирлеге, Якты-Юл бистәсе, Якты Юл ур., 12 йорт янында.

- генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү формасы - җыелыш.

3. Генераль план проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 14 июненнән 01 июленә кадәр эш көннәрендә мәскәү вакыты белән 8.00 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр Мәскәү вакыты белән язма рәвештә Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев урамы, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеше бүлеге яисә Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авылы, Совет урамы, 22 йорт адресы буенча үткәрелә торган гавами тыңлауларны оештыручы адресына кабул ителә.

4. Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- генераль план проекты материалларын, гавами тыңлаулар уздыру беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Генераль план проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне әзерләү буенча эшче төркеме составын кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы Башлыгы карарына кушымта
« ____»________ 2024 №_____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлегенең Генераль планы проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгак әзерләү буенча эшче төркем составы (үзгәрешләр кертү)

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем сәркатибе:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәмәтҗанов И.М. | Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советы җирлекләре белән эшләү секторы мөдире |